Хәмидуллина, Р. «... Чын яшьлек, бәхет ул - биредә»: «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә 60 ел / Р. Хәмидуллина // Мәйдан. – 2023. – №1 (254). – Б. 120-124.

# «...Чын яшьлек, бәхет ул - биредә»

## «Ләйсән» әдәби берләшмәсенә 60 ел

Каләм тибрәтүчеләрне үзенә җыйнаган «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә 50 ел! Күп тә кебек үзе, аз да... Ә тарих өчен бер мизгел генә әле ул. Шул еллар дәвамында берләшмәгә кемнәр генә килмәгән дә, каләменнән тамган ялкынлы сүзләрен кайсы гына укучыга ишеттермәгән.

1970 еллар азагында шәһәребезгә килеп, «Ләйсән» әдәби берләшмәсендә үзенең шәхси шигърият мәктәбен нигезләргә өлгергән күренекле татар шагыйре Кадыйр Сибгатуллин болай дип яза:

*Мәңгелеккә үтеп бара торган*
*кешелекнең без бер буыны.*
*Алып кара,*
*өзеп ташлап кара*
*чылбырдагы безнең урынны!*

Бу шигъри юллар безгә, кабат-кабат, үткәннәрне онытып киләчәккә барып булмавын искәртә бит. Тарихны үзгәртә алмаган кебек, берләшмә эшчәнлегенең бер генә чорын да сызып ташлап булмый. Алай гына да түгел, бүгенге көн дәвамчыларының аңа хакы да юк, алар гел эзләнү юлында. Хәтта «Ләйсән»нең оешу вакыты да күздән югалып торган бер арада, «Якты юл» газетасының 1983 ел 24 ноябрь санында Хәниф Хөснуллинның язмасына тап булдык. «...Хәнәфи ага һәм Зәйнәп апа тырышлыгы белән тупланган түгәрәк 1964 елның 24 гыйнваре утырышында әдәби берләшмә исемен алды. Оешу утырышын шагыйрь Зәки Нури үткәрде. Ул утырышка И. Рәхимов, К. Титаев, Р. Нәгыймуллин, Р. Мәүҗиев, М. Әгъләмов, А. Колчерин, М. Таҗиев һәм мин килгән идек. 15 февральдә уздырылган икенче утырышта мине берләшмә җитәкчесе итеп сайладылар»,– ди ул. Шулай итеп, Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлап, яңа эшкә керешкән, «Татарстан яшьләре» газетасы каршындагы әдәби түгәрәктә чарланган яшь шагыйрь җитәкче итеп сайлана. Белүебезчә, эш 1963 елның көзендә башлана. Чаллы шәһәрендә чыгып килүче «Коммунизм байрагы» газетасы редакциясе хезмәткәрләре үз канатлары астына талантлы егет-кызларны җыя башлый.

Менә инде берләшмәнең беренче җитәкчесе билгеле. Ә исеме?.. Бу сорауны без сугыш һәм хезмәт ветераны, композитор, бик күп җырлар авторы Хәмит Булатовның язмасы аша ачыклыйбыз: «...«Коммунизм байрагы» редакциясе каршында оештырылган әдәбият-сәнгать берләшмәсе башта «Чулпан» дип аталган иде. Аны оештыручы газетаның редакторы Хәнәфи Галиевич Маннапов иде. Берләшмәнең даими секретаре Заһидә Нәбиуллина булып, ул һәр утырышның беркетмәсен язып бара иде. Соңрак берләшмәгә «Ләйсән» исеме бирелде». Менә бит, тарих ничекләр безгә бәян итә. Ә “Ләйсән” исеме аңа бик кызык кына ябышып кала. Бу хакта Мәхмүт Газизов сүзләрен искә төшерәм: “Язучы Шәүкәт Гаделша бирде аңа “Ләйэсн” исемен”, - диде ул. Тарихларга кереп калырлдык исем өчен без менә кемгә рәхмәтлебез.

Оештыручы Хәнәфи Маннапов берләшмәнең эшчәнлегенә үтә дә игътибарлы була. Аның бу хакта әйткән язмасыннан бик күп гамәлләрнең шаһиты булабыз:

«...1965-1966 еллар әдәби берләшмәнең чәчәк ату чоры булды. Туплана килгән көчләрне кирәгенчә, юнәлешле тәрбияләү өчен, без әдәби берләшмәнең эшен, билгеле бер программа буенча, планлы рәвештә алып барырга тырыштык. Яшьләрне туплауга,

үстерүгә, әдәби хезмәтләрен дөньяга чыгаруга һәм үзләрен дә халык массасы алдына чыгаруга бөтен көчебезне, мөмкин кадәр вакытыбызны биреп эшләдек. Берләшмәдә катнашучы яшь каләм көчләре арасыннан бер генә шагыйрь, язучы яки драматург үсә алса да, әдәби берләшмә үзенең максатына ирешкән, димәк, көчебез бушка китмәгән дип саный идек».

Ул чор җитәкчеләренең башкарган эшләренә сокланмый мөмкин түгел, куйган максатларын, шул еллар бәяләве белән әйтсәк, йөз процентка арттырып үтәгәннәр.

1970 еллар башы. Бу елларда әдәби берләшмәнең даны еракларга тарала. Алгарак үтеп шуны җиткерәсе килә, Гигант төзелеш чоры республикабызга бер генә шагыйрь, язучы яки драматург кына бирми, ул биргән язучыларның санын билгеләү дә кыен. Ул заманнар сулышын Х. Хөснуллин болай тасвирлаган:

*Безнең еллар – бөек төзелеш чоры,*
*Шагыйрьләргә эшләр җитәрлек.*

Иҗат түгәрәгенә яшьләр агыла. Алар, КАМАЗ төзүдә актив катнашып, яшьлек, мәхәббәт хисләрен шигырьләрендә *чагылдыралар.*

*Көнен дә, төнен дә эш кайный Чаллыда,*
*КАМАЗны төзибез онытып ялны да;*
*Бирәү дә омтылмый тарихка керергә,*
*Тик белә: чын яшьлек, бәхет ул – биредә.*

Шул еллар шаһиты Мөнип Газарның «Чаллыдан хат» шигыреннән өзек булды бу. «..Чын яшьлек, бәхет ул – биредә».

Шик юк, яшьләр нигез сала, яшьләр төзи КАМАЗ гигантын. Иҗатчыларның роле монда һичшиксез зур була. Тикмәгә генә Кадыйр Сибгат «Хыял» поэмасын тудырмый. Тагын кем, кайсысы болай әйтә алган әле.:

*Яңа Чаллы – яңа әкиятнамә.*
*Елъязмасы кыска.*
*Тарихы зур.*
*Хыялларның таза канатлары.*
*Яши Чаллы,*
*замананы аңа*
*алып керә Тукай пар атлары!*

Төзелеш мәйданнарында, хыял канатларында гына туа аладыр мондый шигъри юллар.

Яңа Чаллы калка. Иҗат кешеләре алны-ялны белми хезмәт итә. Нигез ташы салынганнан алып, әсәрләре һәм ялкынлы сүзләре белән эшчеләрне һәм төзүчеләрне, инженер-техник хезмәткәрләрен һәм җитәкчеләрне яңадан-яңа төзелешләргә рухландырып торалар.

Әдәбият әһелләре Чаллы төзелә башлаган чордан ук шәһәр елъязмасын да, аның тарихын да, халык күңелендә тоткан урынын да чын әдәби телдә кешеләр күңеленә гамьгә төреп сала киләләр. Шәһәр үсә, матурлана. Ул елларның шаһитлары бик күбесе инде юк. Ләкин, аларның карашын һәрвакыт тоеп яшибез. Алар калдырган әсәрләрне, һәрдаим асылына төшенеп, аңлап укырга тырышабыз. Алар бит яшь буынга, киләсе көнгә өмет баглап, горурланып яшәгән һәм иҗат иткәннәр. Алай булмаганда, Мөдәррис Әгъләмов болай ук дулкынланып язмас иде:

*Яңа гасыр керә...*
*Бар ышаныч –*
*Шул дәвердә*
*Яшәр яшьләрдә.*

«Ләйсән» ул – ике гасыр иҗатчыларын бәйләүче берләшмә. Яр Чаллыда һәм Кама аръягы төбәгенең башка урыннарында җиң сызганып иҗат итүче язучыларның күбесе диярлек «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе мәктәбен үткән. Аларның каләменнән, бернәрсәгә карамый, матурлык, кешелеклелек сыйфатлары тама.



«Ләйсән» утырышыннан соң. Беренче рәт (сулдан): Рина Асылбаева, Сәлимә Шәрипова,
*Энҗе Мөэминова, Венера Хәбибрахманова; икенче рәт: Равил Лотфуллин, Мәхмүт Газизов, Хәмит Булатов, Идрис Рыскужин, Рәшит Юнысов, Равил Вәлиев, Фаяз Дунай,*
*Миркадәм Маташин. «Энергетик» мәдәният сарае. 14 февраль, 1975 ел*



*Йөгез, бер фикерләшеп I алыйк! Сулдан: Кадыйр Сибгатуллин, Мәхмүт Газизов, Петр Прихожан, Хәниф Хөснуллин, Тәбрис Гыймазетдинов, Альберт Сафин. | 1975 еллар*

«Ләйсән»дә. Беренче рәт (сулдан): Сәлимә Шәрипова, Хәмит Булатов, Эдуард Касыймов; икенче рәт-. Мәхмүт Газизов, Равил Вәлиев, Әхәт Гайнуллин,
*Нурулла Гаптуллин, Хәниф Хөснуллин, Равил Лотфуллин. 1975 еллар*





г/1әйсән»нең шеф-консультантла-
ры - язучылар Галиәхмәт Шаһи,
Айрат Суфиянов, Амур Фәләх
янәшәсендә.
Беренче рәттә (сулдан):
Рушания Гыйләҗева,
Әлфия Габдрәшитова,
Фәйрүзә Шәрипова,
Айрат Суфиянов, Галиәхмәт
Шаһи; икенче рәттә:
Роза Хәмидуллина,
Рәзинә Сәетгәрәева, Зимфира
Исламова, Амур Фәләх, Равил
Мостафин, Рафыйк Сафин,
Айрат Суфиянов, Рәкит
Аллабирде.
2013 ел



Мамадыш язучылары
бездә кунакта. 19
декабрь, 2015 ел



Сулдан уңга: Флорит Хәми- тов, Галиәхмәт Шаһи, Айрат Шәйхетдинов, Рәзиф Дәүләт Бикбаулы, Фәния Хаммато- ва, Александра Балакаева, Рушания Гь 1Й- ләҗева, Роза Хәмидуллина. 2019 ел

*Шул дәвердә*
*Яшәр яшьләрдә.*

«Ләйсән» ул - ике гасыр иҗатчыларын бәйләүче берләшмә. Яр Чаллыда һәм Кама аръягы төбәгенең башка урыннарында җиң сызганып иҗат итүче язучыларның күбесе «Ләйсән» мәктәбен үткән. Аларның каләменнән, бернәрсәгә карамый, матурлык, кешелеклелек сыйфатлары тама.

Мең еллык әдәбияты булган татар милләте Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат иткән, инде мәңгелеккә атлаган әдипләр ядкарьләренең һәм әле бүген дә каләм үткенлеген җуймаган ләйсәнлеләр хезмәтенең китап булып басылып чыгуын күрергә тиеш иде. Шул арны истә тотып, 2007 еллардан башлап, бүгенге көнгә кадәр әдәби иҗат берләшмәсе әгъзалары һәм аларның иҗат үрнәкләре белән якыннан таныштыруны максат итеп куйган «Ләйсән тамчылары» (2007), «Ләйсән» - моңлы бишегебез» (2009), «Моң дулкынында» (2010), «Әдәби Чаллы» (2020), «Әдәби Чаллы күгендә» (2021) исемле китаплар дөнья күрде. «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзалары турында мәгълүмат туплау эше дәвам итә.

Ләйсәнлеләр бүген дә республика, шәһәр һәм район матбугатында үз әсәрләре белән даими катнашып киләләр, китаплар бастырып чыгаралар. Алар арасында җитмеш алтынчы елларда ук «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсендә каләмен чарлаган, унбер китап авторы Равил Мостафин, үз әсәрләре белән халык күңелен яулаган, дистәдән артык китап авторы Зифа Кадырова, шигырьләре җырларга күчкән авторларыбыз: Зөлфия Нигманова, Кадрия Наил, Асия Хәсәнова, Рәфыйк Сафиннар бар; мәсәлләр, шигырьләр, хикәяләр тупланган дүрт китап авторы Рушания Гыйләҗева, җырчы-шагыйрь-композитор да булган кызларыбыз Зөлфия Җиһан, Флера Коләхмәт, Фәридә Сәхәбиева иҗатлары белән горурланабыз. «Ләйсән»дә каләм чарлаган Айрат Шәйхетдинов, Рамил Шәмсетдинов, Нәкыя Динмөхәммәтова, Гөлия Гыйләҗевалар - КАМАЗ хезмәткәрләре, Гөлфия Фәйзрахманова - артистка, Гөлнара Әхмәтшина, Гөлназ Хәсәнҗанова - хисапчылар, Миләүшә Сәләхова - сатучы, Гөлсинә Төхбәтуллина - пешекче, Гөлсәрия Басыйрова - журналист, Регина Миргалимова - тәрбияче, Гүзәлия Исламова - мәдәният хезмәткәре, Зәбир Хәлимов, Зинфира Кәримова, Дилбәр Әхәтова, Фәйрүзә Шәрипова - укытучылар, Фәнис Нуретдинов - армспорт буенча мөмкинлекләре чикле спортчылар арасында дөнья чемпионы, Рим Гыйльметдинов, Разиф Дәүләт Бикбаулы - хәрби хезмәткәрләр, Флорит Хә- митов - табиб... Күңел халәте, күңел кушуы белән яңадан-яңа авторлар әдәбият мәйданында үз урыннарын эзләвен дәвам итәләр. Каләм тибрәтүчеләрнең һәркайсының үз язмышы, һәркемнең үз урыны бар.

«Ләйсән»леләр бүгенге көндә үзләренең шеф-консультантлары Галиәхмәт Шаһи, Рәзинә Сәетгәрәева, Рәкит Аллабирде, Айрат Суфияновларга бик тә рәхмәтле.

Төбәгебез язучылары турында мәгълүмат туплау эше тукталып торырга тиеш түгел, ул дәвамлы булсын иде. Киләчәктә дә «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсен гел үсештә, киң колачлы иҗат мәйданында күрәсе килә.

**Роза ХӘМИДУЛЛИНА, 2007 елдан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе житәкчесе, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре.**